ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 декабрь 2021ел № 7864

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2020 елның 15 декабрендәге 3/3 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 25 декабрендәге 7326 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшләүче табиб-белгечләргә, клиник-лаборатор диагностика табибларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында нигезләмәнең 2 пунктына, «100 000 (йөз мең)» сүзләрен «200 000 (ике йөз мең)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов